Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Биектау авылы 2020 елның 26 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Норматив актны “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 11 абзацны өстәргә: “муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча”.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Фәтхетдинов урамы, 10 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге башлыгы И.И.Камалиев